СОВЕТ ШАДЧИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Молодежная, д.18, с. Шадчи, Мамадышский район, Республика Татарстан, 422145

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШӘДЧЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Яшьләр ур., 18 нче йорт, Шәдче авылы, Мамадыш районы, Татарстан Республикасы,422145

тел.(факс): (85563) 2-52-24; e-mail: Shad.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение — Карар

« 20 » сентябрь 2017 ел — № 2-24

Референдум үткәрү инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 ел, 12 июнь, 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, "Җирле референдум турында" 23.03.2004 № 23-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 12 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Шәдче авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Түбәндәге мәсьәлә буенча җирле референдумны үткәрергә:
««Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2018 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

1. **Торак пунктлар чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү:**

янгын гидранты җайланмасын сатып алу һәм урнаштыру:
Иске Мочалкино торак пункты

**2. Торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:**

Шәдче ( Г.Тукай урамы – 600 м., М.Җәлил урамы-600 м.), Ямаш (Мирная урамы – 650 м.)авыллары урамнарында юлларны вак таш җәеп ремонтлау;

**3.Торак пункт территориясен төзекләндерүне оештыру:**

Юкәче, Яңа Мочалкино авылларында чишмә төзекләндерү ;

**4. Торак пункт чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү:**

Вахит авылында су торбалары алыштыру.

«ӘЙЕ» «ЮК»

2. Әлеге карарны муниципаль берәмлек Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл жирлеге Башлыгы В. В. Шрыковка йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Шәдче авыл жирлеге башлыгы,
Совет рәисе /В.В.Шрыков /